Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара
авыл җирлеге Советы
КАРАР

«13» октября, 2022 ел № 35

Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Иске Йорт торак пунктында «Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Иске Йорт авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 28 ноябрендәге 1 номерлы халык җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча халык җыены үткәрүне билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә Зур Кукмара авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. 2022 елның 24 октябренә 16 сәгать 00 минутка «Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Иске Йорт авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 28 ноябрендәге 1 номерлы Иске Йорт авылы халык җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча халык җыены үткәрүне билгеләргә. Җыенны Иске Йорт авылы Үзәк урамынды 23 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл клубы янында үткәрергә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Кукмара муниципаль районының Иске Йорт торак пунктында «Кукмара муниципаль районы Зур Кукмара авыл җирлегенең Иске Йорт авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре турында» 2021 елның 28 ноябрендәге 1 номерлы халык җыены карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә ризамы:

«РИЗА» «КАРШЫ»

2 пунктның 7 пунктчасын киләсе редакциядә бәян итәргә:

«7.Җеназа кирәк-яраклары өчен склад бинасын төзү, генератор һәм инвентарь сатып алу, проект-смета документациясен эшләү»

3.Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Җирлек башлыгы Р.Р. Хәнәфиев